Республика Татарстан
ВЕРХНЕСИМЕТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422068, Республика Татарстан, с.Верхний Симет, ул. Советская, 32
тел. 45-0-19

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СИМЕТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422068, Татарстан Республикасы, Югары Симет авылы , Совет урамы, 32 йорт
тел. 45-0-19

e-mail: Bsim.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
03.02.2020

КАРАР
№ 2

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 августында 14 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Югары Симет авыл җирлеге Советы к а р а р кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 августында 14 номерлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:
   1.1. Нигезләмәнең 1 пунктында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача куллaнучылар кооперативы, " сүзләрен төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/simet адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә калдырам.

Югары Симет авыл җирлеге башлыгы — И.Р.Әхмәдуллин